# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

Татарстан Республикасы Конституциясенең
84 һәм 89 статьяларын үзгәртү турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

**1 статья.** 84 статьяның икенче өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Татарстан Республикасы Дәүләт Советына территория сайлау округыннан сайланган депутат, кагыйдә буларак, парламентта даими эшли".

**2 статья.** 89 статьяның икенче өлешендәге 12 һәм 13 пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"12) парламентта даими нигездә эшләүче депутатларның санлы составын билгеләү һәм аларны сайлау;

13) Татарстан Республикасы халык депутатлары арасыннан Дәүләт Советы Президиумын оештыру, Татарстан Республикасы халык депутатлары арасыннан Дәүләт Советының даими комиссияләрен һәм Парламент тикшерүе комитетын оештыру һәм сайлау".

**3 статья.** 89 статьяның өченче өлешендәге 8 һәм 9 пунктларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"8) парламентта даими эшләүче депутатларның санлы составын билгеләү һәм аларны сайлау;

9) депутатлар арасыннан Дәүләт Советы Президиумын оештыру, депутатлар арасыннан Дәүләт Советының даими комиссияләрен һәм Парламент тикшерүе комитетын оештыру һәм сайлау".

П. Әлеге Законны басылып чыккан көненнән гамәлгә кертергә.

Татарстан Республикасы
Президенты М.Шәймиев

Казан шәһәре,
1995 елның 30 марты
№ 17